ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№469

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«28» 09. 2015ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең
2013 елның 15 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек башкаручы махсус коммерциячел булмаган оешма (региональ оператор) һәм махсус исәп хуҗасы тарафыннан белешмәләр тапшыру тәртибен раслау турында” 151 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

2015 елның 29 июнендәге “Россия Федерациясенең Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында” 176-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

**боерык бирәм:**

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2014 елның 28 гыйнварындагы 15 номерлы, 2014 елның 5 мартындагы 35 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән 2013 елның 15 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек башкаручы махсус коммерциячел булмаган оешма (региональ оператор) һәм махсус исәп хуҗасы тарафыннан белешмәләр тапшыру тәртибен раслау турында” 151 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. “3 бүлек. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек башкаручы махсус коммерциячел булмаган оешма (региональ оператор) һәм махсус исәп хуҗасы тарафыннан белешмәләр тапшыру тәртибе (алга таба – Тәртип)” бүлегенең 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.1. Региональ оператор, махсус исәпләрнең хуҗалары капиталь ремонт фондын формалаштыру буенча мәгълүматны ай саен, хисап аеннан

соң килүче икенче айның 10 нчы көненә кадәр ТФМ МАС системасына кертә”.

2. Тәртипкә карата 2 номерлы кушымтаны яңа кушымта булып килүче редакциясендә бәян итәргә.

3. Әлеге Боерык белән Инспекция башлыклары урынбасарларын, бүлекләрнең башлыкларын һәм Инспекция хезмәткәрләрен имзалатып таныштырырга.

4. Хокукый идарәгә әлеге Боерыкны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгында теркәлүен тәэмин итәргә.

5. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башлык С.А. Крайнов.